| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ МОНАШЕВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГОПОСЕЛЕНИЯ<br>МЕНДЕЛЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ МОНАШЕВО АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№84**

**28.04.2023 ел**

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Монашево авыл җирлеге Советының
2021 елның17 июлендәге 38 номерлы
карарын гамәлдән чыккан дип тану турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.2 өлеше һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 8 өлеше нигезендә «Муниципаль хезмәт турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, «Муниципаль вазыйфа йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар йә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2023 елның 17 мартындагы 10/13-13 номерлы аңлатмалары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашво авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Монашево авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү хакында» Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл җирлеге Советының 2021 елның 27 июлендәге 38 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга

2. "Муниципаль вазыйфага яки контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфасына дәгъва кылучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яки контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәт характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Монашево авыл

җирлеге Советының  2023 елның 1 мартындагы 80 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга

3. Әлеге карарны Монашево авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмати стендларга, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына урнаштырып игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында Монашево авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга www.mendeleevsk.tatar.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль-мәдәни мәсьәләләр, законлылыкны, хокук тәртибен һәм кеше хокукларын саклау буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Менделеевск муниципаль районының
Монашево авыл җирлеге Советы рәисе Р.Ф.Иосифов